ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2022 Мөслим авылы № 660

**Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Мөслим муниципаль районы мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнары, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законнар нигезендә Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләсенең балаларын караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) ) алына торган түләүдән азат итәргә.

2. Күрсәтелгән ташламаны, өлешчә мобилизация кысаларында белем бирү оешмасында тәрбияләнүченең ата-анасын (законлы вәкиле) хәрби хезмәткә чакыру турында хәрби комиссариат белешмәсе нигезендә бирергә.

3. Әлеге карарда каралган ташлама гражданин өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт үткән чорда бирелә.

4. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Мөслим муниципаль районының мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләреннән тәрбияләнүчеләрне финанслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-мәдәни үсеш буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**